“Раслыйм”

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
“Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең
җир биләмәләреннән файдалану һәм
төзелеш кагыйдәләре комиссиясе рәисе

________________________И.Ф. Рәхимов

2019 елның 20 нче июне
№ 9

Ачык тыңлаулар буенча
**Нәтиҗә**

ТР ЧМР “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге башлыгының “Ачык тыңлауларны билгеләү турында”гы 2019 елның 19 нчы апрелендәге 8 номерлы һәм 2019 елның 23 нче маендагы 12 номерлы карарлары нигезендә, ачык тыңлаулар 20.06.2019 ел, 10.00 сәгатьтә Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының зур залында түбәндәге адрес буенча узды: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 йорт.

**Ачык тыңлауларда каралган мәсьәләләр:**

Җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү һәм җир кишәрлегендәге капиталь төзелеш объектында рөхсәт ителгән иң чик параметрлардан читләшүгә рөхсәт бирү:

- кадастр номеры 16:54:160307:68, мәйданы 661,42 кв.м., адресы: Татарстан Республикасы , Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре,Чернышевский урамы, 98 нче йорт – “Мөһим товарлар кибете” зонасындагы Ж-1 “Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы” өлешендә;
- кадастр номеры 16:54:100402:200, мәйданы 6112 кв.м., адресы: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Ленин урамы, 40 А йорты.

**Катнаштылар:**

| | |
|---|---|
| **Комиссия рәисе –** И.Ф. Рәхимов | ЧМР шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе |
| **Комиссия сәркатибе -** М.Р.Бибишев | ЧМР “ГиИР” МБУ җитәкчесе |
| Ф.С.Хәйруллина | “Роспотребнадзор”ның ТР буенча Чистай, Спас районнарында территориаль идарәсе начальнигы |
| М.Ю.Исхакова | ТР ЧМР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы башлыгы |
| А.А. Шумилов | ТР ЧМР Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы |

**Карар ителде:**

1. Җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү һәм җир кишәрлегендәге капиталь төзелеш объектында рөхсәт ителгән иң чик параметрлардан читләшүгә рөхсәт бирү буенча ачык тыңлауларны узды дип санарга.
2. Гр. Гусейнов Казыйм Алисаф Оглы мөрәҗәгате буенча, кадастр номеры 16:54:160307:68, мәйданы 661,42 кв.м., адресы: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Чернышевский урамы, 98 нче йорт – “Мөһим товарлар кибете” зонасындагы Ж-1 “Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы” өлешендәге җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү.

3. Гр. Нигъмәтуллина Миңнегөл Хәмит кызының мөрәҗәгате буенча, кадастр номеры 16:54:100402:200, мәйданы 6112 кв.м., адресы: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Ленин урамы, 40 А йорты җир кишәрлегендәге капиталь төзелеш объектында рөхсәт ителгән иң чик параметрлардан читләшүгә рөхсәт бирү.

4. Әлеге нәтиҗәне ТР Хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Комиссия сәркатибе: _______________________М.Р.Бибишев